| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.01.2023 Казан ш № 22

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 21.07.2015 ел, №490 боерыгы белән расланган Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 июлендәге 490 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 23.03.2017 №171, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 24.06.2019 №494, 05.11.2019 №919, 21.04.2020 №257, 14.07.2020 №516, 16.10.2020 №735, 18.05.2021 №320, 17.11.2021 №845, 25.04.2022 №304 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.01.2023 ел, №22 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 июлендәге 490 номерлы боерыгы белән расланган Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.2 пунктында «һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3 пунктта:

2.3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3 пунктын өстәргә:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.4 пунктын өстәргә:

«2.3.4. Айлык акчалата түләүне билгеләү турындагы карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Айлык акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

айлык акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар номеры һәм

датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар;

айлык акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

2.4.3 пунктта «, телефонга СМС-хәбәр белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза, банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп имзаланган электрон рәвештә (тиешле мәгълүматларны гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);

2) чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың (балаларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе – бала тууны теркәү чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан башкарылган очракта;

3) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка (кызлыкка) алу турында

таныклык күчермәсе, әгәр айлык акчалата түләү билгеләү уллыкка (кызлыкка) алынган балаларга карата гамәлгә ашырылса;

4) гариза бирелгән айга кадәрге соңгы өч календарь ае өчен гаиләнең һәр әгъзасы акчалата һәм натураль формада алган керемнәр турында документлар, андыйларга түбәндәгеләр керә:

отставкага киткән судьялар тәэмин итүгә гомер буе айлык түләү;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүве;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;

гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;

5) Административ регламентка 6 нчы кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән

башкарылган очракта, мөрәҗәгать итүче булып тормаган зат тарафыннан бирелә, күрсәтелгән зат хәбәрсез югалган дип танылган яисә эзләнүгә игълан ителгән һәм аның урнашу урыны вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнмәгән очраклардан тыш);

6) вәкаләтле затлар өчен ышаныч кәгазе, әгәр айлык акчалата түләү билгеләү өчен гаризаны вәкаләтле зат тапшырса.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән шәхсән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган документларның күчермәләре төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, гади электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.»;

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарыннан);

инвалид баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарыннан);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе

Эчке эшләр министрлыгыннан);

шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан);

инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә сәләтен чикләүнең өченче дәрәҗәсен үз эченә алган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

инвалид баланың даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булуы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы затларга билгеләнгән компенсация түләвенең законлы вәкиле тарафыннан алынуы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм башка түләүләрне) алу турында (халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт органнарыннан);

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан түләнә торган пенсия һәм башка социаль түләүләрне алу һәм аларның күләмнәре турында;

физик затлар алган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтеннән);

социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләрне алу һәм аларның күләмнәре турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмавы турында (Федераль салым хезмәтеннән).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы, гаризаның яшәү урынына караган урын буенча тапшырылмавы;

гариза формасында, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында интерактив формадагы гаризада мәҗбүри

юлларны корректлы (тулы итеп) тутырмау (төгәл, тулы тутырмау яисә дөрес тутырмау).

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

2.8 пунктта:

2.8.2 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлары булуы.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.8.3 пунктын өстәргә:

«2.8.3. Әгәр гариза һәм документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: КФҮ дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсенең телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәк бүлекчәсендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу

мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.

2.14.6. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша гариза биргәндә, айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр электрон формада җибәрелә.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.»;

3.2.1 пунктның беренче һәм икенче абзацларын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) Үзәк бүлекчәсенә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлекчәсе белгече шәхсән, телефон, электрон почта ярдәмендә, Татарстан

Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.»;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче айлык акчалата түләү билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктына туры китереп, документларны (документларның күчермәләрен) кушып тапшыра.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) җибәрү фактын һәм датасын раслау мөмкинлеген бирелә торган ысул белән, почта аша җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизация уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.1 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин

ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Үзәк бүлекчәсенә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.»;

3.3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында телдән хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк

бүлекчәсе белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон  почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон  почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

эшсезлек буенча пособие күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт органнарыннан);

пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм күләмнәре турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

социаль түләүләр күләме турында (социаль яклау органнарыннан).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.

3.4.3. Айлык акчалата түләү билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлекчәсе белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарына);

инвалид баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә

органнарына);

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондына);

инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә сәләтен чикләүнең өченче дәрәҗәсен үз эченә алган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына);

инвалид баланың даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булуы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына);

хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы затларга билгеләнгән компенсация түләвенең законлы вәкиле тарафыннан алынуы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына);

эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм башка түләүләрне) алу турында (халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт органнарына);

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсия һәм башка социаль түләүләрне алу һәм аларның күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына);

физик затлар алган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтенә);

социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләрне алу һәм аларның күләмнәре турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмавы турында (Федераль салым хезмәтенә).

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле орган ведомствоара гаризаларны карый һәм законнарда билгеләнгән срокларда җавап җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

3.4.4. Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителәә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.6 пунктының икенче абзацында:

«телефонга смс-хәбәр итеп» сүзләрен төшереп калдырырга;

«электрон почта» сүзләреннән соң «һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына» сүзләре белән тулыландырырга;

3.8.3 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша) айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.»;

4.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә башка кешеләр
каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә)
мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган
инвалид балаларга өстәмә рәвештә
айлык акчалата түләү билгеләү

буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә
муниципаль районында (шәһәр округында)

Гариза №____
_________ 20__ ел.

Мин, ____________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафын-нан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес:
______________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
эш итү нигезе:
______________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________
Билгеләвегезне сорыйм ____________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
яши торган адрес: _______________________________________

_____________________________________________________________________.
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
_____________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)
______________________________________________________________________,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә

рәвештә айлык акчалата түләү турында» 2012 елның 7 мартындагы 188 номерлы карары нигезендә даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балага өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү_______________________________________________

______________________________________________________________________
(Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Мөрәҗәгать итүченең гаилә составы:

| | Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәклесен билгеләргә * |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

--------------------------------

* дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар билгеләнә.

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында булмавын раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата ________________________________
______________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукында чикләнмәгән

_______________ ______________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________.
(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)
Билгеләнгән түләүне түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

әлеге счетка күчерү юлы белән ________________________________________
(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлекчәсе аша ________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ___________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:
почта адресы буенча язма формада ______________________
электрон почта адресы буенча ________________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ____________________________________________________________________________
(«әйе» яки «юк» дип күрсәтергә)

Мөрәҗәгать итүче:
_______________________________________ _________ «__» ________ 20__ ел.
(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә нигезендә белдерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
(имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ____________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

---

Аеру сызыгы
Язу-белдерү
Гариза бирүченең теркәлү №___________
Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә
Документлар кабул ителде _____________ ___________ ____________ __________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү билгеләү турында карар

№____ «__» ________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
_______________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________
Билгеләргә:_______________________________________________________________

| № | Социаль ярдәм чарасының исеме | Билгеләнү датасы | Түләү вакыты: ____ башлап _____ кадәр |
|---|---|---|---|
| | Даими рәвештә башка кешеләр кайгыртуына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү | | |

Түләү ысулы ____________________________________________________________
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе мөдире
________________________________________
муниципаль районы (шәһәр округы) _________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече
________________________________________
муниципаль районы (шәһәр округы) _________________________ ____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
язма формада – почта адресы буенча ______________________
электрон почта адресы буенча _________________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

______________________________________

(«әйе» яки «юк» дип күрсәтергә)

бүлекчә белгече ___________________________ _____________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

___________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә)
мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү
билгеләүдән баш тарту турында карар

№____ «__» ___________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_____________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы _______________________________________________

Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган, 18 яшенә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тартырга

Баш тарту сәбәбе: ___________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе мөдире

_________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) _____________________ __________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

_________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) _____________________ __________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
язма формада – почта адресы буенча ________________________________

_________________________ электрон почта адресы буенча
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша
____________________________________________
(«әйе» яки «юк» дип күрсәтергә)

бүлекчә белгече_________________________________________ ______________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №____ бүлекчәсенә

________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: _________________________________________________
___________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
___________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ исеме, аның сериясе,
___________________________________________________________________,
номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ____________________________________________

Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карарда җибәрелгән _____________№______________.
(карар датасы) (карар номеры)

Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту)
турында мәгълүмат алуга риза ___________________________________________
(почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша)

«__» __________ 20__ ел. ________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Регламентка 6 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Шәхси мәгълүматлар эшкәртүгә ризалык

Мин, ____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
**теркәлгән адресы:** ______________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

шәхесне раслаучы документ__________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъекты документының исеме, документның номеры, аны бирү датасы һәм биргән орган турында белешмәләр)

Даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү максатында шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (тапшыруга, бирүгә, таратуга) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
туган көне, ае, елы;
шәхесне раслаучы документ төре;
шәхесне раслаучы документ белешмәләре;
яшәү урыны;
элемтә өчен телефон номеры;
почта адресы;

социаль хәле;

мөлкәти хәле;

шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларына кагылышлы башка мәгълүматлар.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә: җыюга, системалаштыруга, туплап баруга, саклауга, тәгаенләштерүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга (шул исәптән тапшыруга), шәхси булуын бетерүгә, куллана алмаслык итеп чикләп куюга, юкка чыгаруга ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар белән башкарылачак гамәлләр исемлеге.

Оператор шәхси мәгълүматларны, субъектның шәхси мәгълүматларын эшкәртүнең автоматлаштырылган чараларын кулланып, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да эшкәртә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык гамәлдә булган вакыт: әлеге ризалык имзаланган көннән алып субъектның шәхси мәгълүматларны язмача кире алган көненә кадәр гамәлдә була.

______________________________________________ ________________ _______________
(шәхси мәгълүматлар субъектының ФИА (соңгысы – булган очракта) (имза) (дата)

Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

шәхесне раслаучы документ_____________________________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъекты документының исеме, номеры, документ бирү датасы һәм биргән орган турында белешмәләр)

яши торган адресы: __________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектын теркәү адресы)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның $10^1$ статьясы, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «Тарату өчен шәхси мәгълүматлар субъекты рөхсәт иткән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү таләпләрен раслау турында» 2021 елның 24 февралендәге 18 номерлы боерыгы нигезендә, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округындагы Үзәк бүлекчәсе аша шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (тапшыруга, бирүгә, таратуга) ризалыгымны бирәм,

__________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме ,атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

шул исәптән _______________ мәгълүмат ресурсын да кулланып, даими рәвештә башка кешеләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ булган, 18 яше тулмаган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү максатында.

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

туган көне, ае, елы;

шәхесне раслаучы документ төре;
шәхесне раслаучы документ белешмәләре;
яшәү урыны;
элемтә өчен телефон номеры;
почта адресы;
социаль хәле;
мөлкәти хәле;
шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларына кагылышлы башка мәгълүматлар.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә: җыюга, системалаштыруга, туплап баруга, саклауга, тәгаенләштерүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга (шул исәптән тапшыруга), шәхси булуын бетерүгә, куллана алмаслык итеп чикләп куюга, юкка чыгаруга ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар белән башкарылачак гамәлләр исемлеге.

Оператор шәхси мәгълүматларны, субъектның шәхси мәгълүматларын эшкәртүнең автоматлаштырылган чараларын кулланып, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да эшкәртә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык гамәлдә булган вакыт: әлеге ризалык имзаланган көннән алып субъектның шәхси мәгълүматларны язмача кире алган көненә кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматлар ата-ана (законлы вәкил) аларны эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгели торган шәхси мәгълүматларның категорияләре һәм исемлеге, шулай ук билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге (шәхси мәгълүматлар субъектының ихтыяры буенча тутырыла): ______________________________________.

Алынган шәхси белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыручы оператор тарафыннан шәхси мәгълүматлар бары тик билгеле бер хезмәткәрләр өчен катгый рәвештә генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген бирә торган эчке челтәре буенча яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып тапшырыла ала торган яисә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмауны күздә тоткан шартлар (шәхси белешмәләр субъекты ихтыяры буенча тутырыла) ________________________________

_____________________________________________ ________________ __________
(шәхси мәгълүматлар субъектының законлы вәкиленең ФИА (соңгысы – булган очракта) (имза) (дата)»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.